КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2024 ел, 5 ноябрь | г.Казань | № 962

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Архивның уку залында архив документларыннан (күчермәләреннән) һәм белешмә-эзләү чараларыннан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү» дәүләт хезмәте сыйфатының стандартын раслау турында» 2017 ел, 12 декабрь, 974 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Архивның уку залында архив документларыннан (күчермәләреннән) һәм белешмә-эзләү чараларыннан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү» дәүләт хезмәте сыйфатының стандартын раслау турында» 2017 ел, 12 декабрь, 974 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 13 декабрь, 1119 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» дәүләт бюджет учреждениесе эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү, Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан дәүләт биремен үтәүне мониторинглауны тәэмин итү максатларында, аны финанс белән тәэмин итү Татарстан Республикасы бюджетыннан гамәлгә ашырыла, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

әлеге карар белән расланган «Архивның уку залында архив документларыннан (күчермәләреннән) һәм белешмә-эзләү чараларыннан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү» дәүләт хезмәте сыйфатының стандартында:

1.1 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. «Архивның уку залында архив документларыннан (күчермәләреннән) һәм белешмә-эзләү чараларыннан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү» дәүләт хезмәтен (алга таба - дәүләт хезмәте) алучылар физик яки юридик зат мәнфәгатьләрен тәкъдим итүче, кирәкле мәгълүматны алу һәм алардан файдалану өчен архив документларына

законлы нигезләрдә мөрәҗәгать итүчеләр юридик, физик затлар яки физик яки юридик зат мәнфәгатьләрен тәкъдим итүче затлар була, шул исәптән чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар.»;

1.2 пунктка «I төркем инвалидлары» сүзләреннән соң «, Икенче бөтендөнья сугышы чорында фашистлар һәм аларның союздашлары тарафыннан булдырылган концлагерьлар, гетто, мәҗбүри тоту урыннарының элеккеге балигъ булмаган тоткыннары, Чернобыль АЭС һәлакәте, Семипалатинск полигонындагы атом-төш сынаулары нәтиҗәсендә радиация йогынтысына дучар булган затлар һәм аларга тиңләштерелгән гражданнар категорияләре, хәрби хәрәкәтләр ветераннары» сүзләрен өстәргә;

2 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең хокукый нигезе

Дәүләт хезмәте түбәндәге норматив хокукый актлар нигезендә күрсәтелә:

«Россия Федерациясендә архив эше турында» 2004 елның 22 октябрендәге 125-ФЗ номерлы Федераль закон;

«Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон;consultantplus://offline/ref=E2BC9298FC58A1D1EC395ABEA6188DE6267935FEC15F026FAC90E396F57056D9BA04CFE9297F8C52933A137BD0e6lBI

Россия Федерациясе Мәдәният һәм массакүләм коммуникацияләр министрлыгы, Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгы, Россия Федерациясе Федераль иминлек хезмәтенең «Россия Федерациясе дәүләт органнарының дәүләт архивларында һәм архивларында саклана торган, сәяси репрессияләргә дучар булган затларга карата җинаять һәм административ эшләр туктатылган материаллардан файдалану тәртибе турындагы нигезләмәне, шулай ук фильтрацион-тикшерү эшләрен раслау хакында» 2006 елның 25 июлендәге 375/584/352 номерлы боерыгы;

Федераль архив агентлыгының «Россия Федерациясенең дәүләт һәм муниципаль архивларында архив документларыннан файдалану тәртибен раслау турында» 2017 елның 1 сентябрендәге 143 номерлы боерыгы;consultantplus://offline/ref=E2BC9298FC58A1D1EC395ABEA6188DE621733FFEC85D026FAC90E396F57056D9BA04CFE9297F8C52933A137BD0e6lBI

Федераль архив агентлыгының “Россия Федерациясе Архив фонды һәм дәүләт һәм муниципаль архивларда, музейларда һәм китапханәләрдә, фәнни оешмаларда башка архив документларын саклауны, комплектлауны, исәпкә алуны һәм куллануны оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 2 мартындагы 24 номерлы боерыгы;

“Татарстан Республикасында архив эше турында” 2017 елның 20 июлендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләре сыйфатының стандартлары турында» 2009 ел, 30 июнь, 445 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының аерым дәүләт учреждениеләре һәм аерым дәүләт учреждениеләре

төрләре кисемтәсендә дәүләт хезмәтләре һәм башкарыла торган һәм башкарыла торган эшләр исемлегенең Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән финанслана торган якынча исемлеген раслау турында» 2015 ел, 29 сентябрь, 726 нчы карары.»;consultantplus://offline/ref=E2BC9298FC58A1D1EC3944B3B074D0ED217162F1C0560B3CF9C0E5C1AA20508CE84491B07938C75F97270F7BD771E29077eAl5I

4.3 пунктның икенче җөмләсенә «инвалид балалар» сүзләреннән соң «, Икенче бөтендөнья сугышы чорында фашистлар һәм аларның союздашлары тарафыннан булдырылган концлагерьлар, гетто, мәҗбүри тоту урыннарының элеккеге балигъ булмаган тоткыннары, Чернобыль АЭС һәлакәте, Семипалатинск полигонындагы атом-төш сынаулары нәтиҗәсендә радиация йогынтысына дучар булган затлар һәм аларга тиңләштерелгән гражданнар категорияләре, хәрби хәрәкәтләр ветераннары» сүзләрен өстәргә;

5.3 пунктның 5.3.5 пунктчасында «мөрәҗәгать итүчеләр» сүзен «дәүләт хезмәтен алучылар» сүзләренә алмаштырырга, «кулланучылар» сүзен «алучылар» сүзенә алмаштырырга;

6.2 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы һәм «Янгын куркынычсызлыгы турында техник регламент» 2008 елның 22 июлендәге 123-ФЗ номерлы федераль законнарда, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә Янгынга каршы режим кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 16 сентябрендәге 1479 номерлы карары, Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының «Янгынга каршы көрәш системалары» кагыйдәләре җыелмасын раслау турында» 2020 елның 31 августындагы 628 номерлы боерыгы белән билгеләнгән янгын куркынычсызлыгы таләпләренә. Янгын сүндерү җайланмалары автомат рәвештә эшли. Проектлау нормалары һәм кагыйдәләре;»;

7.1 пунктта «мөрәҗәгать итүчеләр» сүзләрен «дәүләт хезмәтен алучылар» сүзләренә алмаштырырга;

7.4 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.4. Дәүләт архивының эш графигы: көн саен, шимбә һәм якшәмбедән кала. Уку залы өчен: дүшәмбе, сишәмбе, чәршәмбе 8.30 сәгатьтән 17.30 сәгатькә кадәр, пәнҗешәмбе 9.00 сәгатьтән 20.00 сәгатькә кадәр, җомга 8.30 сәгатьтән 17.30 сәгатькә кадәр, төшке аш 12.00 сәгатьтән 12.45 сәгатькә кадәр. Һәр айның соңгы җомгасы - санитар көне.»;

9.1 пунктның беренче абзацында «кулланучылар» сүзен «дәүләт хезмәтен алучылар» сүзләренә алмаштырырга;

10.1 пунктның 10.1.1 пунктчасына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«реставрация-консервация эшләре уздырганчы, торышы канәгатьләнерлек булмаган дип танылган архив документыннан файдалану мөмкинлеген чикләү.»;

11 бүлек таблицасында:

1 пунктның 2 графасында «кулланучылар» сүзен «дәүләт хезмәтен алучылар» сүзләренә алмаштырырга;

2 пунктның 2 графасында «кулланучылар» сүзен «дәүләт хезмәтен алучылар» сүзләренә алмаштырырга;

12.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12.1. Мөрәҗәгать итүче шулай ук түбәндәге очракларда шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәтен алучының дәүләт хезмәтен күрсәтү турындагы соратуын теркәү вакыты бозылу;

2) дәүләт хезмәтен күрсәтүнең билгеләнгән срогы бозылу;

3) дәүләт хезмәтен алучыдан әлеге Стандартның 3 бүлегендә каралмаган документларны таләп итү;

4) әлеге Стандартның 3 бүлегендә каралган документларны кабул итүдән баш тарту;

5) әлеге Стандартның 10 бүлегендә баш тарту нигезләре каралмаган булса, дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту;

6) дәүләт хезмәте күрсәткәндә дәүләт хезмәтен алучыдан түләү таләп итү;

7) Россия Федерациясе законнары нигезендә эшләр, документлар, белешмә-эзләү чараларын, матбугат басмаларын бирү срогын яисә тәртибен бозу;

8) әлеге Стандартның 10.1 пунктындагы 10.1.1.1 пунктчасында туктатып тору нигезләре каралмаган булса, дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору.»;

12.2 пунктның беренче абзацында «күпфункцияле үзәк яисә күпфункцияле үзәкне гамәлгә куючы» сүзләрен төшереп калдырырга;

12.3 пунктта «мөрәҗәгать итүче» сүзләрен «дәүләт хезмәтен алучы» сүзләренә алмаштырырга, «күпфункцияле үзәк аша» сүзләрен төшереп калдырырга;

12.4 пунктта:

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«дәүләт хезмәте алучы  физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы - булган очракта), яшәү урыны турында белешмәләр яисә дәүләт хезмәтен алучы юридик затның исеме, урнашу урыны турында белешмәләр,  вәкаләтле затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы - булган очракта), шулай ук элемтә телефонының номеры (номерлары), электрон почтаның адресы (адреслары) һәм дәүләт хезмәтен алучыга җавап җибәрелергә тиеш почта адресы;»;

бишенче абзацта «мөрәҗәгать итүче» сүзләрен «дәүләт хезмәтен алучы» сүзләренә алмаштырырга, «Гариза бирүче» сүзләрен «Дәүләт хезмәтен алучы» сүзләренә, «мөрәҗәгать итүче» сүзләрен «дәүләт хезмәтен алучы» сүзләренә алмаштырырга;

12.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12.7. Дәүләт архивына кергән шикаять шикаятьне карау буенча вәкаләтләр бирелгән вазыйфаи зат тарафыннан аны теркәгән көннән соң 15 эш көне эчендә, ә  Дәүләт архивы, Дәүләт архивының вазыйфаи заты дәүләт хезмәтен алучыдан документлар кабул итүдән  йә эшләр башкаруда җибәрелгән хаталарны, документларны, белешмә-эзләнү чараларын, басмаларны төзәтүдән баш тарткан очракта - аны теркәгән көннән алып биш эш көне дәвамында каралырга тиеш.»;

12.8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12.8. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча Дәүләт архивы түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

шикаятьне канәгатьләндерә, шул исәптән эшләрне, документларны, аларга белешмә-эзләү чараларын, матбугат чараларын биргәндә Дәүләт архивы тарафыннан

җибәрелгән хаталарны Россия Федерациясе законнары нигезендә төзәтү рәвешендә;

шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарта.»;

12.9 пунктчада «мөрәҗәгать итүче» сүзләрен «дәүләт хезмәтен алучы» сүзләренә, «мөрәҗәгать итүчегә» сүзләрен «дәүләт хезмәтен алучыга» сүзләренә алмаштырырга;

12.10 пунктта «мөрәҗәгать итүче» сүзләрен «дәүләт хезмәтен алучы» сүзләренә алмаштырырга;

12.11 пунктта «мөрәҗәгать итүче» сүзләрен «дәүләт хезмәтен алучы» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин